СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

19 ФЕВРАЛЬ, 1997ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 19 (8031) | Бәясе билгеләнгәнчә.

## Хезмәтләре белән мактаулылар



Таныш булыгыз: рәсемдә «Сельхозтехника» район берләшмәсенең механикалаштырылган отряды механизаторы Геннадий Андрианов. Ул Т - 150 тракторында эшли, ә берләшмәдә бу төр техника өчен эшнең һичкайчан бетеп торганы юк. Геннадий Николаевич исә үзенә тапшырылган хезмәтне һәрчак җиренә җиткереп үтәргә күнеккән. Шуңа коллективта да хөрмәт зур ана.

**Рәсемдә: тракторчы Г.Андрианов.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## МӨҺИМ МӘСЬӘЛӘЛӘР ТИКШЕРЕЛДЕ

Узган дүшәмбедә район хакимиятенең кече залында район хуҗалыклары җитәкчеләре катнашында үткән киңәшмәне хакимият башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев алып барды. Киңәшмәне ачып, ул алда торган отчет җыелышларын үткәрү буенча эшлекле күрсәтмәләр бирде, анда хуҗалыкларны үзгәртеп кору төп мәсьәлә булып торырга тиешлеген ассызыклады. Бу хакта сүзне район авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе экономисты Р.Р.Йосыпов дәвам итте. Ул үзгәртеп коруның ике этабы, арендa подряды һәм хуҗалык эчендәге кооперативлар оештыруның үзенчәлеге турында сөйләде, бу җәһәттән практик киңәшләр бирде.

Киңәшмәдә техниканың язгы кыр эшләренә әзерлеге турында информацияне авыл хуҗалыгы идарәсенең техника куркынычсызлыгы буенча инженеры Г.С.Зарипов ясады.

Ремонт эшләре таләп ителгән дәрәҗәдә бармый. Башка еллардан аермалы буларак, авыл хуҗалыгы машиналары - бөртек чәчкечләр, культиваторлар, [illegible]малар ремонтлауда да кыенлыклар бар. Тракторлар белән эш аерата кискен. Бүгенгә барлык тракторларның 59 проценты, ә чылбырлы тракторларның 40 процентлабы гына сафта. Чыгыш ясаучы аерата акрын селкенгән хуҗалыкларны тәнкыйть утына алды. Ул берочтан быел орлык төягеч һәм минераль ашламалар төягечләр булдыруга аерата игътибар соралуына, аларның әле күпләп җитеп бетмәвенә басым ясады. Чыгышының ахырында ул март башына техниканы агрегатлау, 1 апрельгә тракторларны ремонтлауны төгәлләү бурычын куйды, хезмәтне саклау темасына кагылды.

Аның чыгышын «Сельхозтехника» район берләшмәсе баш инженеры А.Н.Кузнецов тулыландырды.

Сүз терлекчелек темасына күчеп дәвам итте. Идарәнең терлекчелек бүлеге начальнигы Ф.Г.Минһаҗев тыңлаучылар игътибарын февральдә продукция җитештерүнең торышын анализлау белән бергә җитди мәсьәлә - малларны каплатуга юнәлтте. Февральдә узган 16 көндә продукция алуны киметү күзәтелә, ул аны малларны асрау, ашату технологиясен тупас бозу белән аңлатты. Малларны каплату да гафу ителмәслек акрын бара. Оратор бу җәһәттән конкрет хуҗалыкларны атап мөгезле эре терлекләрне, дуңгызларны каплату 20 мартка төгәлләнергә тиешлеген ассызыклады.

Авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе начальнигы Ә.Н.Рәхмәтуллин, теманы дәвам итеп, шәхси сектордан сөт җыюның сүлпән оештырылуына борчу белдерде, районның баш ветеринария врачы Г.Ш.Кыямов малларның баш санын саклау, алар арасында йогышлы авырулар булдырмау юнәлешендә эшнең тиешенчә оештырылмавын конкрет мисаллар китереп бәян итте.

Шуннан соң чыгыш ясаучылар төрле темаларга кагылдылар: район Советы рәисе урынбасары Е.К.Савинов газлаштыруны тизләтү, җир ресурслары һәм җир реформасы комитеты рәисе Р.Х.Хәсәнов җир пайлары белән эшләү, район пенсия фонды уполномоченные В.Г.Хоменко ассоциацияләрнең пенсия фондына кертемнәр бүлүе, хакимият башлыгы урынбасары Ф.Р.Ногманова авыл җирләрендә агитмасса эшләрен яңарту мәсьәләләрен күтәрделәр.

Киңәшмәгә йомгакны Ю.В.Терентьев ясады.

## 1 НЧЕ ФЕВРАЛЬДӘН - ЯҢА БӘЯЛӘР

Күптән түгел «Норлатгаз» эксплуатация - производство идарәсенә «Газпром» республика акционерлык җәмгыятеннән газ хуҗалыгының газ белән тәэмин итү системасын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтүгә яңа бәяләр прейскуранты алынды. Хәзер челтәр газы булганда профилактик хезмәт күрсәтү ул нинди газ плитәсеннән файдалануга карап 11.900 - 15.800 сумга төшәчәк. Баллон газы булганда бу бәяләр югарырак: 2 комфоркалы плитәгә профилактик карау үткәрү өчен 18.800 сум, 3 комфоркалыга - 20.800, 4 комфоркалыга - 22.800 сум түләргә кирәк булачак. Дөрес, түләү елга бер генә башкарыла.

Өйгә авария службасы слесарен чакыру һәр кулланучыга 7.500 сумга төшәчәк. Җылылык регуляторын алыштыру 11.800, газ плитәсен алыштыру - 13.700, газ колонкасын яңаны кую 23.900 сум белән бәяләнә. Иң кыйммәт хезмәт булып казанны алыштыру санала, ул - 49.500 сум.

Газчылар шактый югары бәяләрне газ җиһазларын төзек тоту, техник карауны нәтиҗәле итү зарурилыгы белән аңлаталар.

Белгечләр әйтүенчә, «Газпром» газ ягулыгына бәя арттыру юнәлешендә дә җитди ниятләр белән яши. Хәзергә бу мәсьәлә эшләнә генә әле. Шуңа да бүгенге арзан челтәр газы иртәгә шактый саллы бәягә төшсә, гаҗәпләнмәгез. Моның өчен сезгә иң отышлысы - газ хисаплагычлар алу. Заявкалар кабул ителә.

**Т.АЛЕКСЕЕВА.**

## ЗАПАС ЧАСТЬЛӘР БИК КИРӘК

Яз - тау артында түгел. Басуга чыгар көннәргә вакыт көннән - көн кими. Шуңа да бүген район хуҗалыкларында авыл хуҗалыгы техникасын тизрәк төзәтеп бетерү зарурилыгы аңлашыла. «Октябрьскагропромснаб» базасы коллективы да бу эшкә үз өлешен кертергә омтыла. Соңгы 10 - 15 көн эчендә генә дә база төрле чыганаклар аркылы 162 миллион сумлык запас частьләр юнәтте. ДТ - 75 тракторлары өчен тормоз ленталары, гидробүлгечләр, насослар кайтардылар алар. Иң элек шунысын да әйтергә кирәк, базадан запас частьләр юнәткән хуҗалыклар оттырмаслар: биредә бәяләр чагыштырмача арзан. Накладканың бер данәсе, мәсәлән, 9 мең сум тора. Казанда гидрошлангларны 100 мең сумнан да арзанракка алып булмаса, биредә аның бәясе 75 - 85 мең чамасы.

Соңгы вакытта «Октябрьскагропромснаб» базасына авыл хуҗалыгы машиналары өчен дә запас частьләр шактый кайтты. Чәчкечләр өчен орлык үткәргеч, культиваторлар өчен табаннар да хуҗалыклар өчен ярап куячак.

**Ф. ГӘРӘЕВ.**

## Белми калмагыз

### Миншакир Бакиров призына

Шимбә көнне Түбән Норлат авылы мәдәният йортында Әфганстанда хәрби хезмәт вакытында һәлак булган Түбән Норлат авылы егете Миншакир Бакиров призына милли көрәш буенча ярышлар үтәчәк. Анда районыбызның яшь көрәшчеләре катнашачак, шулай ук күрше районнардан да кунаклар килүе көтелә.

## Икенче Бөтендөнья татар конгрессы булачак

***Татар халкының киләчәккә милли - мәдәни үсешен тәэмин итү чараларын эшләү, Татарстаннан читтә яшәүче ватандашларыбыз белән икътисадый һәм мәдәни элемтәләрне киңәйтү максатында һәм Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма Комитетының тәкъдимен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев 1997 елның 28 - 29 августында Казанда Икенче Бөтендөнья татар конгрессын уздыру турында Указ чыгарды.***

***Татарстан Республикасы Премьер - министры рәислегендә конгрессны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзелде.***

***Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Бөтендөнья татар конгрессы фонды белән берлектә финанслауның бюджеттан тыш чыганакларын файдалануның да күздә тотып, конгрессны әзерләү һәм уздыру чараларын финанслау тәртибен билгеләргә кушылды.***

## Районыбыз хәбәрләр тормышыннан

### Килешүгә кул куелды

Хөкүмәт йортында Татарстан Министрлар Кабинеты, Профсоюзлар федерациясе, промышленность предприятиеләре ассоциациясе һәм Сәүдә - промышленность палатасы арасында төзелгән килешүгә кул куелды. Документка Премьер - министр Ф.Мөхәммәтшин, Профсоюзлар федерациясе рәисе Ф.Гайнуллина, Татарстан Сәүдә - промышленность палатасы генераль директоры Ш.Агеев, Татарстан промышленность предприятиеләре ассоциациясе президенты А.Пахомов имза салдылар.

Килешү Татарстанның икътисадый һәм социаль прогрессы дәүләт программасын тормышка ашыру чараларын үтәүгә, житештерүне тотрыкландыру шартларын тудыруга, инфляция темпларын киметүгә, халыкны эш белән тәэмин итүгә, хезмәт ияләренең законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен ныгытуга, производствода эшләүчеләр хезмәтен һәм сәламәтлеген саклауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

### Фиркагә биш яшь

Оешуына биш ел тулу уңаеннан Татарстан Республика партиясенең чираттагы пленумы булды. Партия рәисе Хәлим Гайнуллин, аның урынбасары Фираз Харисов, шулай ук Рүзәл Йосыпов, Рәшит Вәгыйзов, Тәлгат Шиһабиев чыгышларында хәзерге ыгы - зыгы заманда фирканең роле турында сүз барды. Белгечләрнең республикадагы икътисади кыенлыкларның сәбәпләре хакындагы чыгышлары да депутатларның игътибар үзәгендә булды. Бәйсезлеккә халыкара хокук яулаган Ичкерия дәүләтенең кичәге, бүгенге һәм киләчәк көрәшенә дөрес бәя бирү кирәклеге мәсьәләсе күтәрелде.

### Акцияләр кыйммәтләнә

Халыкара фонд базарында «Татнефть» акционерлык җәмгыяте акцияләре көннән - көн кыйммәтләнә. Бездәге номиналь бәясе 10 мең сум итеп билгеләнгән акция монда баштарак 45 долларга тинләшсә, соңга таба 62 долларга күтәрелде.

### Канга сусау

Хастаханәләрдә канга мохтаҗ булган авырулар өчен нәкъ менә шул кан юк. Сәбәбе - җан җылысын тапшыручыларга акча түләмиләр. Ә 100 миллиграмм кан тапшырган һәр донорга 40 мең сум акча кирәк. Әлеге аяныч хәлне тикшерү буенча хөкүмәт комиссиясе төзелде.

### «Аргументлар һәм фактлар»ның Татарстанга дигәне дә... Чабаксарда басыла

Бик популяр «Аргументлар һәм фактлар» газетасының Татарстан газета - журналлар нәшриятында (ТГЖИ) басыла торган тиражының сыйфаты һич тә укучыны канәгатьләндерерлек түгел иде.

Шуңа күрә «Аргументлар һәм фактлар», укучыларның күпсанлы теләкләрен исәпкә алып, газетаны басуны Казаннан Чабаксарга күчерергә карар кылды.

Шулай итеп, «А и Ф» моннан ары офсет ысулы белән басыла башлады. Типографияне алыштыру мәшәкатьле һәм өстәмә чыгымнар сорый, әлбәттә. Аның каравы, элеккеге һәм хәзерге газетаның, бигрәк тә андагы рәсемнәрнең сыйфатында җир белән күк аермасы.

**22 февраль көнне 17.00 сәгатьтә район культура йортында Ватанны саклаучылар көненә багышланган театрлаштырылган бәйрәм концертына чакырабыз.**

Аның программасында:

- Ватанны саклаучылар белән очрашу;
- Үзешчән сәнгатьтә катнашучы иң яхшы ансамбльләр һәм солистлар чыгышы;
- Тынлы оркестр астында бию программасы.

Концертка керү - ирекле.

# АКЧАСЫ БУЛСЫН ДИП ЭШЛӘРГӘ, БУЛГАНЫН САКЛАП ТОТАРГА

## Елның финанс программасы: средстволарны максатчан тоту, бюджетның керем өлешен тулыландыру.

Халык депутатлары район Советының агымдагы елга бюджет кабул итүгә багышланган тугызынчы сессиясе узган атнада районның социаль тормышында җитди вакыйга булды. Хакыйкать хакына шуны әйтергә кирәк (һәм сессия мөнбәреннән чыгыш ясаган депутатлар үзләре дә моны таныды), бу сессия элеккеләренә бары тик формасы буенча гына охшаш иде, ә эчтәлеге ягыннан бөтенләй башка төрле булды. Залда элеккечә гәзит кыштырдатып, бер - берсе белән сөйләшеп утырулар урынына эшлекле тынлык хакимлек итте, ә тәкъдим ителгән теләсә нинди карар проекты өчен битараф төстә кул күтәрергә әзерлек депутатларның зур кызыксынучанлыгы белән алышынды. Хәер, чынлыкта да шулай булырга тиеш иде шул ул, ник дисәң, ул көнне гаять мөһим мәсьәлә - 1997 елга бюджетны формалаштыру мәсьәләсе каралды бит. Ә бу бюджеттагыларга хезмәт хакы ничек түләнәчәк, медицинага һәм мәгарифкә, шул исәптән мәктәп балаларын ашатуга да акча каян алыначак... дигән күпсанлы сорауларга җавап табу дигән сүз бит. Шуңа күрә бюджетның һәм керем, һәм чыгым статьяларының барысы да җентекләп, хуҗаларча санап - исәпләп эшләнелгәнме - депутатлар боларга карата бик җитди булдылар.

Сүз дә юк. Иң элек шуны уңай яктан билгеләп үтәргә кирәк, район хакимияте башлыгы урынбасары - финанс бүлеге мөдире **Р.Г.БИЛАЛОВ**ның доклады соңгы елларда беренче тапкыр буларак, аеруча проблемалы, үткенлеге, анализлы итеп һәм смета - финанс дисциплинасын җитди бозуларга юл куйган җитәкчеләргә ишетүе бик үк күңелле дә булмаган ваклыкларга кадәр тукталып эшләнгән иде. Әйтик, салым түләүче гади кешеләрнең матди хәле начар булган хәлдә өсте - өстенә затлы җиңел машиналар, кабинетларга кыйммәтле эш җиһазлары алу, штатларны чамасыз арттыру үзе генә дә ни тора, ә бит аларның барысы өчен дә акча күп очракта ахыр чиктә шул мескен салым түләүче кесәсеннән чыга. Докладчы шулай ук өч предприятие - сәүдә базасы, сөт - май комбинаты һәм ДРСУның банкротлыгы турында да хәбәр итте.

Аннан соң район Советы план һәм бюджет - финанс комиссиясенең өстәмә докладе белән чыккан комиссия рәисе депутат **Х.Н.АТАУЛЛИН** бюджетка һәм аның кайбер нечкәлекләренә гомуми бәяләмә бирүдән тыш районда физик культураның җитәрлек финансланмавын билгеләп үтте. Бюджеттан бүленгән акчаның тотылуына контроль булмауны раслау өчен ул 1996 елның октябрендә тикшерү вакытында Норлат урамнарындагы 567 фонарьның бары 275е генә янып торганлыгы ачыкланганлыгын, ә шәһәр электр челтәре, МППның битарафлыгыннан файдаланып, лампочкаларның 90 проценты янып торган иттереп акча каерганлыгын мисалга китерде. Комиссия рәисе район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллинның авылларда мәктәпләрне, балалар бакчаларын, башка учреждениеләрне газлаштыру һәм кирәкле ремонт эшләре үткәрүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү өчен 5 миллиард сумны үзәкләштерү турында карар чыгаруын зур канәгатьләнү белән билгеләп үтте. Менә бу киләчәкне күздә тотып эш итү инде. Бюджет агымдагы моментларны да фаразларга тиеш. Ел озын бит - нинди генә ихтыяҗга акча кирәк булмаска мөмкин.

Районның баш финансчысы һәм депутат комиссиясе җитәкчесенең эшлекле чыгышлары актив фикер алышуларга этәрде. Монда депутат **Л.Н.ГАЗИЗУЛЛИНА** тон бирде. Районның яңа җитәкчесенең эшчәнлеген уңай бәяләү, 53 нче СМУның элеккеге башлыгын үзенә йорт салганда чама хисен онытып җибәргәнлеге өчен, район элемтә узелы җитәкчелеген районда нормаль телефон элемтәсен тәэмин итүдәге җитешсезлекләре өчен ачыктан - ачык тәнкыйтьләүдән тыш, ул тимер юлчылар коллективының үзләре түли торган салымнарның Ульяновск өлкәсенә китмичә, Октябрь районы бюджетында калуын теләүләре турында хәбәр итте. Сүзенең ахырында Л.Н.Газизуллина тиешле органнарга предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләренә карата дәүләт акчасының бәрәкәтле тотылуы өчен таләпчәнлекне көчәйтергә кирәклеген әйтте.

Депутат **З.А.ШАБАЕВ** үзе җитәкчелек итә торган өлкәдә хәлне яхшы белгәнгә күрә, бу турыда сессиягә тезисларсыз гына да объектив мәгълүматны җиткерде. Бүленгән 19,9 миллиард сум тулысынча тотылган. Бер үк вакытта ул кайбер, аерым алганда Мамык җирле үзидарә Советлары рәисләренең акчаның статьялар буенча тотылышына йомшак контроль ясауларына игътибар юнәлтте. Зәкәрия Абдуллович участок шифаханәләрендәге искергән җиһазларны, бигрәк тә ренген аппаратурасын заманчаракка алыштыру кирәклеген аерым билгеләп үтте. Ул шулай ук шәһәр предприятиеләрендә медицина пунктларын сакларга теләүләре хакында әйтте. Алар эшчеләр, пенсионерлар ихтыяҗы өчен ачылган бит. Нишләп кешеләрне шул социаль уңайлыктан да мәхрүм итәргә?

Ары таба фикер алышуларда тагы берничә депутат чыгыш ясады. **В.И.ГАВРИЛОВ** җитәкчеләрне бюджет средстволарын рациональ кулланырга чакырды, депутатлар **Ә.Н.МИНАЗОВ** һәм **М.С.МОРАТОВ**, бюджет проектын тәкъдим ителгән вариантта хуплап, үз коллективларының «Норлат - Октябрь элеваторы» акционерлык җәмгыяте һәм райпоның авырткан нокталары турында сөйләделәр. Соңгысында, сүз уңаеннан, проблемалар тагы артты - райпо үз балансына районара сәүдә базасын, аның белән бергә - базаның бурычларын да алды... База бүген банкрот итеп игълан ителде. Аның сәүдә складлары буш. Хәл катлаулы, биредә җитди чаралар кирәк.

Район Советының план һәм бюджет - финанс даими комиссиясе члены депутат **Р.Ш.ХАФИЗОВ** үз чыгышын тулысынча җирле бюджетка түләүләр мәсьәләсенә багышлады. 1997 елның 1 гыйнварына җирле бюджет 21 млрд. сум акча җыеп җиткермәде.

Йортлар төзү кече комбинаты директоры **А.С.ХӘЙРУЛЛИН**ның чыгышы катнашучыларда зур кызыксыну уятты. Соңгы тапкыр райсовет сессиясендә 1991 елда катнашуын искә төшереп, А.С.Хәйруллин 1997 елга район бюджеты проектында эшмәкәрлек хәрәкәтен хупларлык дәлил күрмәвенә борчу белдерде. Дөресен әйткәндә, ул әле Норлатта яралгы хәлендә генә, шуңа да, кызганычка каршы, бюджетның аерым өлешен формалаштыруда роль уйнамый. Шәһәрдә «Кодак» тибындагы төсле фототасмаларны ачыгайту салоны, шуңа охшаш башка көнкүреш хезмәте күрсәтү үзәкләре юк. Мәсәлән, шәхси чәчтараш юк, районда берләнбер нотариус, шуңа халык күрше районнарга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр. Кече эшмәкәрлекне үстерергә, аңа шартлар тудырырга, кредитлар бүлергә кирәк, диде иптәш Хәйруллин, ә актив кешеләр исә табылыр. Шул очракта кече бизнес белән мәшгуль кешеләрнең дә саны артыр, бу исә яңа эш урыннары булдыруга булышыр иде.

Чыгышларны тәмамлап депутат **М.М.ХУҖИН** һәм «Дуслык» район газетасы баш мөхәррире **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ** сүз алдылар. Беренче оратор район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллинга шактый авыр «мирас» эләгүен әйтеп үтте. Проблемаларны хәл итү җитәкчеләр, депутатлар, хезмәт коллективлары членнарының тырышлыгы, омтылышы, энергиясенә бәйле булачак. Р.Ф.Җамалиев сессия барышында барган сөйләшүне район прессасы җитәкчесе позициясеннән эшлекле һәм җитди итеп бәяләде. Бер ел элек коллективның үзлегеннән компьютер технологиясен үзләштерүен искәртеп, ул финанс яктан ярдәм мәсьәләсен күтәрде.


Сессиядә каралган мәсьәләне йомгаклап, халык депутатларының район Советы рәисе, хакимият башлыгы **Ф.С.СИБАГАТУЛЛИН** үз чыгышын тулысынча районның финанс - кредит проблемаларына багышлады. Депутатлар тарафыннан мәсьәләнең җитди, аңлап кабул ителүенә канәгатьлек белдереп, ул түбәндәгеләргә басым ясады. Күрелгән чаралар район бюджетын 34 процентка ныгытырга мөмкинлек бирделәр. Икенче вариантта ТР Финанс министрлыгы тарафыннан азрак күләм күздә тотылган иде. Оратор агымдагы елда беренче чиратта бюджетның керем өлешен тулыландыру турында уйларга кирәклеген ассызыклады. Монда салымнарны тулы күләмендә җыю элеккечә үк мөһим чыганак булып кала. Ә бу өлкәдә резервлар бар. Һәм шактый саллылар, дип басым ясады Ф.С.Сибагатуллин һәм фикерен «Татнефтепром»ның Зүзәй нефть промыселы практикасыннан ышандыргыч саннар белән дәлилләде. Район бюджетының керем өлешенә күпме салым каралган шулкадәр күчерелергә тиеш, без моңа ирешергә тырышачакбыз, дип тәмамлады ул чыгышының бу өлешен.

А.С.Хәйруллинның сессиядәге чыгышын уңай бәяләп, Ф.С.Сибагатуллин кече бизнесны үстерүгә булышлык итәргә ышандырды. Бу төр эшчәнлекнең район икътисадына өлешен арттырырга кирәк. Шул ук вакытта Ф.С.Сибагатуллин аракы әйберләре сатудан алынган реаль керемнәрен яшереп калучы кайбер эшмәкәрләр («Ләйсән» кибете, «Мажор» ширкәте һәм башкалар) адресына каты тәнкыйть сүзләре әйтте.

- Без салым инспекциясеннән (Г.Ә.Миннегалиев) һәм кулланучылар хокукларын яклау район комитетыннан (Р.Г.Суфиянов) да нәтиҗәлерәк эш көтәбез, - диде оратор һәм сүзен йомгаклап залдагыларның игътибарын авылдагы һәр гаиләнең матди хәлен яхшырту буенча урында ук тормышка ашырылырга тиешле зур һәм гамәли программага юнәлдерде. Шәхси секторда терлекләрнең баш санын ишәйтү, йорт яны участокларын зурайту, яңа промыселлар ачу - болар һәммәсе бүген авыл халкына аяктан егылмаска реаль булышырга мөмкин. Моңа барьяклап һәм сүздә генә түгел, ә эш белән булышлык итү - җирле үзидарә Советларының турыдан - туры бурычы.

1997 елга район бюджеты турындагы карар бертавыштан кабул ителде. Аның керем өлеше 99268 миллион сум, чыгым өлеше 107054,0 миллион сум булу каралган, ягъни бюджет дефициты ахыр чиккәчә киметелгән. Хәзер шул средстволарны вакытында җыйнау һәм булганнарын хуҗаларча тоту бурычы тора. Шуңа да депутатлардан берсенең район бюджетының үтәлеше барышын әледән - әле тикшереп торырга тәкъдим итүе очраклы түгел. Бу гомуми җаваплылыкны күтәрер иде.

**Т.НАЗАРОВА.**




## Киекле иҗатчылары

***Бүген «Нәниләргә кучтәнәч»не газетабызның даими авторы Роза Маслахова бүләк итте. Ул Киекле авылы мәктәбендә укытучы булып эшли. Шунда ук шигырь сөюче укучыларны берләштергән «Яшь каләмче» түгәрәге оештырган. Биредә укучылар шигырь белән мавыгуларын рәсем сәнгате белән дә тулыландыралар икән. Роза апа үзе зоология дәресләрен алып бара. Шундыйрак хәлләр дә була дип яза ул.***

Гали, яле, әйтеп кара,
Чебен, камка, умарталар
Кайсы класска керә?

- И апа, билгеле инде,
Ачык булса ишекләр,
Кайсы класс дип тормый,
тула шуның ишеләр.

- Апа үзегез әйттегез,
Сумкалы дип көнгерә,
Ничек соң ул алай булгач,
Куллары да юк тотарга,
Сумка белән йөгерә?

*Өметле күренгән авторларның иҗатларыннан «Кучтәнәч»не Роза апа газета укучыларга да тәкъдим итә.*

## Мәзәкләр
## Иәзәкүэь

Кечкенә кызчык абыйсын йөдәтепме йөдәтә.

Абыйсы нишләсен, тора да тәрәзә пәрдәсен төшереп куя.

- Абый, пәрдәне ач, югыйсә, караңгыны күрми калырбыз,- ди сеңлесе.

***

- Галәви, менә сиңа яңа дәреслекләр алдым.

Кара аны: пычратма!

- Ярар, әни. Мин аларга кагылып та карамам.

***

- Әгәр син миллион тәңкә тапсаң, нишләр идең?

- Яртысын сиңа бирер идем. Ә син нишләр идең?

- Рәхмәт әйтер идем.



*Лилия Садыйкова*
*(4 нче сыйныф)*

### Минем исемем Гөлнара

Минем исемем Гөлнара,
Мин бик акыллы бала,
Иртүк мәктәпкә барам,
«Бишле» билгесе алам.
Иртән иртүк уянам да
Бик әйбәтләп юынам,
Урыннарны җыешам -
Әниемә булышам.
Мине апам Лилия
Ярата, якын күрә,
Мәктәпкә барыр алдыннан
Чәчемне тарап үрә.

### Мин рәсем ясыйм

Мин рәсемнәр ясарга
Бик яратам, дускаем!
Матур итеп ясарга
Тырышам мин көн саен.
Мин рәсемгә төшерәм
Урманнарны, кырларны,
бик матур болыннарны
һәм нәни колыннарны.
Гел рәсемнәр ясыйсы
Килә бит хәзер минем.
Матур рәсем шикелле
Балкысын туган илем.


### Беренче кар

Иртән торып тышка чыктым
Анда ап - ак кар ява,
Җиргә төшкән һәрбер бөртек
Ак энҗе булып яна.

### Кыш


Ап - ак чапанын киеп,
Кыш та килеп җитте бит
Бөтен җиргә ак мамыктай
Юрган ябып китте бит.

*Лилия Сафина*
*(4 нче сыйныф)*



## Башваткыч

### Кем тизрәк?



Бу куш сүзләрдән төзелгән башваткычны чишү өчен җәяләр эчендәге ноктлар урынына бирелгән сүзнең игезәген язарга кирәк. Мәсәлән, (...) - төшем,, шау - (...), - мөлкәт дигән сүзләр явым - төшем, шау - гөр, мал - мөлкәт дигәнне аңлата. Башваткычны дөрес чишсәгез, вертикаль буенча калын сызыклар эчендә ачлык дигән сүзнең игезәген табарсыз.

1. Яна - (...)
2. (...) - йолдау
3. (...) - энеле
4. Киенү - (...)
5. Фәлән - (...)
6. Тап - (...)
7. (...) - ботлы
8. (...) - тилшән
9. (...) - бакыра
10. Иске - (...)




Гөлүсә Яруллина
(11 нче сыйныф)

### ӘБИЕМ

Ак яулыгын бәйләп куя
Җилкәсенә төшереп
Ә чәчләрен җыеп куя
Баш түбәсенә өеп.
Күпне күргән, күп эшләгән
Әбиемнең куллары
Җыерчыклы шул кулларда
Күренә тормыш юллары.
Балачагы аның үткән
Авыр, ач заманнарда.
Тилмереп бәхет эзләп
Киткәннәр еракларга.
Үткәннәрен уйлый - уйлый
Әбием көйләр көйли
Башыннан кичкән хәлләрен
Әкият итеп сөйли.
Иртә белән тора ул
Таң кояшын күрергә
Догаларын кыла ул
Таң кояшын күрүгә.
Ул сагына улларын
Һәм сөекле кызларын.
Ул миңа да дога кыла
Уң булсын дип юлларың!
Кадерле әбкәйләрнең
Кабул була догасы
Игелек кылып аларга
Догаларын аласы.

Илһамия Низаметдинова
(Кизләү мәктәбе, IX сыйныф)

### КЛАССТАШЫМ МИСАЛ ЧИШӘ

Безнең Вәли дәрес саен
Тапкырларга өйрәнә.
Тапкырларга өйрәнгәч
Эше бераз көйләнә.
«Х», «У», «Z»ләр белән
Башым инде катты, ди
Әлҗәбер дәресе үткәч
Бер шатлыгым артты, ди.
Системалап мисал чишү
Әҗәл бер аның өчен
Тәнәфескә чыккач кына
Күрсәтә үзенең көчен.

*Г. Сәгыйров*

### ПЕСНӘКЛӘР ҖЫРЫ

Кыш җиткәч, азык - җим
Табылмый башлады.
Һәм Наил безгә дип
Ашханә ясады.
*Чик - чирик*
*Чик - чирик,*
*Чик - чик - чик.*
Килегез, карагыз,
Күрегез, нинди ул.
Эчендә җим тулы -
Бер бушап тормый ул.
*Чик - чирик,*
*Чик - чирик,*
*Чик - чик - чик.*
Җим булгач курыкмыйбыз
Бернинди салкыннан.
Наилгә зур рәхмәт
Барча кош халкыннан.
*Чик - чирик,*
*Чик - чирик,*
*Чик - чик - чик.*
Күрәмсез, дусларым,
Инде кич җиткән дә.
Капкалап алыйк та
Таралыйк өйләргә.
*Чик - чирик,*
*Чик - чирик.*
*Чик - чик - чик.*

### Игезәкләр



... Өчәү: ике малай бер кыз.
Тәгәрәшеп уйныйлар,
Үкерешеп елыйлар,
һич кенә тик тормыйлар.
Әниләре әрли: җитәр,
Туктагыз - алам чыбык!
Туганчык сез, чукынчыклар,
Бирмәдегез тынгылык!..

### БАТЫР ТӘКӘ

... Бу тәкәнең
мактанырга сәбәбе бар:
Өйгә керде,
Көзгедә зур Тәкә күрде.
Гайрәтләнеп сөзгән иде -
чәлпәрәмә!-
Күрдегезме? -
Тегенең кирәген бирде.

### КАРГА

Багана башында карга
«Кар» да «кар» дип кычкыра,
Ерактан килгән җавапны
Тын калып тыңлап тора.
«Кар» да «кар» дигән сүзләрен
Кабатлый әллә ничә,
Әллә ничә төрле итеп,-
Тыңлыйм да исем китә.
Нәрсә хәбәр итә икән?
Кемнәр икән ишетә?
Тик кызганыч: ни әйткәнен
Аңлап булмый ничек тә.

### Хәйләле Вәли

Ураза тота әби,
Ураза тота әни,
Мин дә тотыйм әле дип,
Кызыгып йөри Вәли.
Аптырата әбине,
Тинтерәтә әнине.
Уятырбыз, диләр дә -
Уятмыйлар Вәлине.
Вәли нәкъ сезнең кебек
Хәйләкәр малай икән:
Уйлап тапкан бит әнә -
Әбине кызык иткән.
... Сәхәр вакыты җиткән,
Әби уянып киткән:
Торып басса - итәген
Нәрсәдер тарта икән.
Тотып бакса - киндерә...
Киндерә буйлап барса,
Икенче оч малайның
Муенында ләбаса.
Коты очкан әбинең:
- Балам буылып үләр.
Уятыйм әле көн дә -
Үзем дә инде... җүләр!

## ФОЛЬКЛОТО

Халыкта шундый акыллы фикер бар: үткәнен оныткан халыкның киләчәге юк, ди ул. Әйе, Татарстанда да халык мирасы күпкырлы һәм бик бай. Һәм менә шул рухи байлыкны - милли әдәбият әсәрләрен өйрәнү балаларда туган телгә, туган якка мәхәббәт тәрбияли, халыкның тарихына, гореф - гадәтләренә, йолаларына карата ихтирам уята.

Халыкның бай мирасы безне хәзер дә шатландыра, күңелгә үтеп керәме икән? Бу сорауга җавап эзләп балалар һәм яшүсмерләр үзәге варислар - отрядлар арасында «Фольклото» конкурсы игълан итте. Уенда мәктәп турларында җиңгән 25 отряд катнашты. Девиз итеп «Җигелдеңме - арбаңны тарт» дигән мәкаль алынды. Конкурста аны тартырга авырсынучылар юклыгы ачыкланды. Көрәштә көчләр тигез иде, шулай да жюри җиңүче командаларны билгели алды. Алар «Сабан туе» (Югары Норлат мәктәбе), «Веселушки» (шәһәрнең 4 нче мәктәбе), «Азамат» (Аксумла), «Родничок» (өченче мәктәп), «Әнисә» (Кычытканлы), «Чунга - чанга» (Түбән Чаллы) командалары булып чыкты.

**Рәсемдә: конкурс бара.**

**М.ГИНЯЕВА.**

**Балалар һәм яшүсмерләр үзәге.**



# 1997 елның икенче яртысына түбәндәге басмаларга февральдән 31 мартка кадәр льготалы язылу уздырыла

| Индексы | Басманың исеме | Ярты елга ничә чыга | Язылу бәясе (сум.) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 3 айга | 6 айга |
| **ГАЗЕТАЛАР** | | | | |
| 40911 | Век (оешмалар өчен) | 26 | 50100 | 100200 |
| 50299 | Век (индивидуаль) | 26 | 30000 | 60000 |
| 50050 | Известия (инд.) | 130 | 33300 | 66600 |
| 32326 | Известия (оешм.) | 130 | 109800 | 219600 |
| 50228 | Крестьянская газета | 26 | 17400 | 34800 |
| 50075 | Медицин. газета (инд.) | 52 | 40500 | 81000 |
| 32289 | Медицин. газета (оешм.) | 52 | 58500 | 117000 |
| 32303 | Московские новости | 26 | 48600 | 97200 |
| 32422 | Московский комсомолец | 130 | 65100 | 130200 |
| 32304 | Москоу ньюс (ингл. тел) | 26 | 29400 | 58800 |
| 39802 | Не может быть | 6 | 12900 | 25800 |
| 32138 | Общая газета | 26 | 31800 | 63600 |
| 31910 | Российская охотничья газета | 26 | 9300 | 18600 |
| 50203 | Российские вести (инд.) | 130 | 30600 | 61200 |
| 50090 | Российские вести (оешм.) | 130 | 218700 | 437400 |
| 50105 | Российские вести (шимбә чыг.) | 26 | 9600 | 19200 |
| 50124 | Советская Россия | 78 | 30600 | 61200 |
| 50122 | Советский спорт | 108 | 78600 | 157200 |
| 50130 | Труд (көндәлек) | 120 | 37500 | 75000 |
| 32068 | Труд (шимбә чыг.) | 26 | 12600 | 25200 |
| 32444 | Финансовые известия | 52 | 31500 | 63000 |
| **ЖУРНАЛЛАР** | | | | |
| 70142 | Вокруг света | 6 | 38700 | 77400 |
| 40970 | Все звезды | 2 | 8900 | 17800 |
| 40930 | Женское здоровье | 3 | - | 47700 |
| 39001 | Закон | 6 | 85200 | 170400 |
| 70424 | Искатель («Вокруг света» журналына кушымта) | 6 | 19200 | 38400 |
| 70663 | Огонек | 26 | 60300 | 120600 |
| 73313 | Природа и охота | 2 | 13900 | 27800 |
| 70770 | Работница | 6 | 28500 | 57000 |
| 70781 | Ровесник | 6 | 29700 | 59400 |
| 72098 | Техника - молодежи | 6 | 35700 | 71400 |
| 32272 | Шестнадцать | 6 | 26700 | 53400 |
| 40950 | Штучка | 6 | 29700 | 59400 |
| **«Аргументлар һәм фактлар» агентлыгы газеталары** | | | | |
| 32123 | Аргументы и факты | 26 | 22800 | 45600 |
| 32128 | АиФ «Здоровье» | 26 | 15600 | 31200 |
| 32130 | АиФ «Я молодой» | 26 | 18300 | 36600 |
| 32321 | АиФ «Жизнь и кошелек» | 12 | 10800 | 21600 |
| 34186 | АиФ «Любовь» | 12 | 15600 | 31200 |
| 32320 | АиФ «Дочки - матери» | 12 | 14400 | 28800 |
| 31912 | АиФ «Семейный совет» | 12 | 10500 | 21000 |
| 32129 | Интерфакс - АиФ | 26 | 59100 | 118200 |
| 50051 | Книжное обозрение | 26 | 24600 | 49200 |
| 50067 | Литературная газета | 26 | 32700 | 65400 |




# ЧАҢГЫЧЫЛАР БОЛГАРДА БУЛДЫ

Агымдагы айның 6 сынан 9ына кадәр Спасс районы үзәге Болгар шәһәрендә чаңгыда узышу буенча республика ярышлары үтте. Анда безнең районнан да вәкилләр катнашты. Алар арасында ДЮКФП тренеры Петр Кузьменковта тәрбияләнүчеләр Е.Яковлев, А.Ерепов, В.Емелин, А.Канарейкин һәм МСОдан С.Бурнаевская катнаштылар. Калганнары - С.Трофимов, Е.Фадеев, В.Ипатов Каравыл Тавы урта мәктәбеннән иделәр.

Шәхси беренчелек ике көн буена дәвам иткән ярышлар нәтиҗәсендә билгеләнде. Е.Яковлев беренче көнне 5 километрга классик стиль белән узышуда финишка беренче булып килде. Әмма икенче көнне ирекле стиль белән узышканда нәтиҗәсе түбән булды һәм шуңа күрә аңа өченче урын белән генә канәгатьләнергә туры килде.

Гомумкоманда исәбендә исә октябрьлеләр алты команда арасында Сарман районы һәм Болгар - 1 командасыннан соң өченче нәтиҗә күрсәттеләр. Бу, билгеле, безне канәгатьләндермәде. Әмма ни эшләмәк кирәк, спортның сәламәтлек өчен бик файдалы булган бу төре белән чын - чынлап, икенче төрле итеп әйткәндә, классик, шулай ук ирекле стиль белән шөгыльләнү өчен база булмау үзен һәрчак сиздерә шул.

Чаңгы сезоны дәвам итә. 23 нче февральдә без Иске Чаллы авылында Советлар Союзы Герое Н.К.Синдряков, 8 мартта Каравыл Тавы авылында шулай ук Советлар Союзы Герое А.И.Кузнецов призларына чаңгы ярышлары үткәрергә исәплибез. Шулар арасында тагын бер ярыш 2 мартта МСО базасында үтәчәк әле.

**Х.ФАТУЧЕВ.**



## Котлыйбыз



Бу көннәрдә хөрмәтле кешебез **Затия Вәли кызы Гайнуллинаның** туган көне - аңа 50 яшь тула. Без аны олы юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз, нык сәламәтлек, чиксез бәхет, әтиебез белән тигез гомер кичерүләрен телибез.

**Хөрмәт белән**
**Яр Чаллыдан Марат Гайнуллин гаиләсе.**



*Норлат шәһәрендә яшәүче кадерле тормыш иптәшем һәм әниебез **Әминә Сәлим кызы Зиннурованы** һәм кызыбыз **Гөлияне** туган көннәре белән тәбриклибез. Аларга исәнлек, озын гомер, бәхет телибез.*

*Безнең күңел һәрчак сезгә*
*Гел тели изге теләк.*
*Җир йөзендә сездән башка*
*Берни юк кадерлерәк.*

***Рафик, Алсу.***

## Котлыйбыз!



Колбай Мораса авылында яшәүче кадерле **әтиебез, бабабыз Хәбибулла Насыйбулла улы һәм аның тормыш иптәше Затия Вәли кызы Гайнуллиннарны** тормышларындагы истәлекле дата - бергә яши башлауларына 20 ел тулу уңаеннан кайнар котлыйбыз. Киләчәктә дә шулай тату яшәп, без балалары өчен үрнәк булып гомер итүләрен, сәламәтлек, бәхет, озын гомер телибез.

**Марат Гайнуллин гаиләсе,**
**Яр Чаллы шәһәре.**



*Хөрмәтле **Затия Вәли кызы Гайнуллинаны** гомер юлындагы олы вакыйга - 50 еллык юбилее һәм тормыш иптәше Хәбибулла Насыйбулла улы белән гаилә коруларына 20 ел тулу уңаеннан кайнар котлыйбыз. Аларның һәр икесенә таза сәламәтлек, бәхетле тормыш, озын гомер телибез.*

***«Мажар» ширкәте коллективы.***

# Белдерүләр реклама

## Шәхси фатирын булдырырга теләүчеләр игътибарына!

***Октябрь хуҗалыкара төзелеш оешмасы администрациясе сезне торак йортлар төзелешенә үз өлешегез белән катнашырга чакыра .***

***Беренчел взнос фатир бәясенең яртысы күләмендә кертелә,*** **тулы исәп - хисап төзелеш тәмамланганнан соң төзелеш материаллары бәясенең инфляциягә бәйле рәвештә үзгәрүеннән чыгып ясала. Йортлар СПТУ бистәсендә салына.**

**Гомуми мәйданның бер квадрат метры 1 миллион 400 меңнән 1 миллион 600 мең сумга кадәр.**

**Моннан тыш, килешү бәясе буенча СПТУ һәм Төзүчеләр бистәләрендә 6 - 8 сутый участогы белән тәмамланып бетмәгән икешәр фатирлы йортлар да тәкъдим итәбез.**

**Шулай ук әзер проект буенча үзебезнең һәм күрше районнарның теләсә кайсы урынында бер яки ике фатирлы теләсә нинди зурлыктагы йортлар салуга да заявкалар алабыз.**

**Нигез кору, стена өю, отделка һәм ремонт эшләре дә башкарабыз, дача йортлары һәм гаражлар салабыз. Бәясе - килешү буенча.**

**Төзелеш тизләтелгән темпта бара. Эшне вакытында һәм сыйфатлы башкарып чыгу гарантияләнә.**

***Сезне Норлатта Завод ур., 1 адресы буенча МСОда көтәбез,***
***тел.: 2 - 12 - 61.***

## Идел Буе региональ наркология үзәге

***Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.***

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

## Бездә генә!

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көнне, 28 февральдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.

***«Консульт информ плюс» юридик консультация - мәгълүмат фирмасы үз предприятиеләрендә тирә - юньне мохитны саклау һәм экология белән шөгыльләнүче һәм тирә - юнь мохитны пычраткан өчен түләүләрне хисаплау эшләрен башкаручыларны укытуны оештыра.***

***Укуларны Татарстан Республикасы экология фондының Көньяк - Көнчыгыш бүлегенең баш белгечләре түбәндәге юнәлешләр буенча уздыра:***

*1. Тирә - юнь мохитны пычраткан өчен түләүләргә исәп - хисап документлары эшләү;*

*2. предприятиеләрдә тикшерү актлары үткәрү;*

*3. Табигатьне саклау чараларын финанслау.*

Укыган өчен (310.000 сум, аңа исәп - хисап һәм финанслау бланклары да керә) түбәндәге адрес буенча түләргә: р/с № 1467019 ОСБ 4683 г.Альметьевск, к/с 600164968, БИК 049202668 РКЦ г.Альметьевск БИК 049202000, ИНН 1644012600.

Укулар 1997 елның 26 февралендә район мәдәният йортының кече залында уздырыла. Башлана иртәнге сәгать 10да.

Үзең белән акча күчерү боерыгының күчермәсен алып килергә.

## Сатабыз

**Шәһәр уртасында бер бүлмәле фатир.** Тел.: 5 - 25 - 35.

***

**Сүтеп алу өчен йорт.**
Адрес: Совет ур., 63.

***

**5 Х 4 метрлы, тәрткесез бура.** Адрес: Тельман ур.: 6 - 30 (кичке 5 тән соң).

***

## Алмаштырабыз

**МТЗ - 82 тракторын (документлары бар) - 1985 елдан да элегрәк чыкмаган Нива яки ВАЗ - 2106, 2107, 2104, 2105 машиналарына.**

Адрес: Тельман ур., 6 - 30 (кичке 5тән соң).

Киекле татар мәктәп - гимназиясе коллективы энесе **Альфред Әнвәр улы Хаҗимoратовның** кинәт үлүе сәбәпле, укытучы Гөлсинә Мортазинаның тирән кайгысын уртаклаша.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2071 данә. Заказ № 5736